**РАСЛЫЙМ**
Татарстан Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе

_______________

**В.Г. Шәйхразыев**

7+

## *“Әниемнең җылы кочагы-2025” конкурсы нигезләмәсе*

Бөтендөнья татар конгрессының
“Әниемнең җылы кочагы” конкурсын үткәрү турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. **Гомуми нигезләмәләр**
1.1. “Әниемнең җылы кочагы” конкурсының (алга таба Конкурс) оештыручылары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты (алга таба Конгресс);
1.2. Конкурс турында Нигезләмә конгресснның рәсми сайтында https://tatar-congress.org/ru/ “Рәсми басма” сәхифәсендә урнаштырыла.
1.3. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла;
1.4. Конкурска бер генә хезмәт килсә/яисә бер хезмәт тә кермәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

2. **Конкурсның максаты һәм бурычлары:**
2.1. Конкурсның максаты – әниләргә хөрмәт тәрбияләү.
2.2. Әниләр хакындагы шигырьләрне популярлаштыру, барлау.
2.3. Бөтендөнья татар конгрессы сайтын, социаль челтәрләрен популярлаштыру.
2.4. Конкурсның төп бурычлары;
— татар гаиләсендә әнинең тоткан роле хакында сөйләү, күрсәтү;
—хатын-кызның төп бурычы — ана булу, балалар тәрбияләү, гаилә учагын саклаучы икәнлеген искәртү;
— Балалар арасында әнинең иң кадерле кеше икәнлеген, аңа карата хөрмәт, ихтирам булырга тиешлеген күңелгә сеңдерү, пропагандалау;
— татар гаиләсенең борынгыдан килгән нигезен барлау.

3. **Конкурсның номинацияләре:**

3.1. Конкурс “Әниемнең җылы кочагы” номинациясе буенча өч категориядә мәктәп укучылары арасында үткәрелә:

1. 1 – 4 нче сыйныфларда укучылар арасында;
2. 5 – 8 нче сыйныфларда укучылар арасында;
3. 9 – 11 нче сыйныфларда укучылар арасында;

3.2. Һәр номинация буенча I нче, II нче, III нче урыннар билгеләнәчәк.

3.3. Жюри конкурс эшләре арасыннан Рәхмәт хатларына лаекларны сайлап алу хокукына ия.

4. **Конкурста катнашучыларга таләпләр:**

4.1. Конкурста Татарстан, Россия һәм чит илләрдә яшәүче 1-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

4.2. Конкурста катнашучы "Конкурс номинацияләре" шартларына туры китереп, әнисе турында үзе иҗат иткән, яисә башка авторның әсәрен сәнгатьле итеп сөйләп («Шигърият» яки «Проза») видеога төшерергә һәм Вконтакте челтәрендә “Әниемнең җылы кочагы” төркеменә урнаштырырга тиеш.

5. **Конкурсны үткәрү шартлары һәм таләпләре:**

5.1. Конкурска тәкъдим ителүче хезмәт видеога яздырыла.

Видеога таләпләр:1920*1080, 16.9 (горизонталь рәвештә), mpg, mpeg2 яки mpeg4 (H264) форматында.

5.2. Конкурста катнашучы әниләр турында язылган әсәрләрне укыганда авторын әйтергә тиеш.

5.3. Вконтакте төркеменә урнаштырылган видео астына катнашучыдан үзенең ничәнче сыйныфта укуын, исем-фамилиясен һәм кайдан булуын язу таләп ителә.

**Бу мәгълүматлар язылмаса, җибәрелгән видеоязма конкурстан төшеп кала!**

5.4. Конкурс эшләрен кабул итү срогы тәмамланганнан соң алынган конкурс эшләре каралмый.

5.5. Конкурска старт 2025 нче елның 1 нче октябрендә бирелә һәм 1 ноябрьдә тәмамлана. Нәтиҗәләр 15 нче ноябрьдә ясала.

5.6. Оештыручылар җиңүчеләрне сайлап ала. Аларның исемнәре Бөтендөнья татар Конгрессы сайтында һәм социаль челтәрләрдә игълан ителә. Җиңүчеләрне бүләкләү көне шулай ук Конгресс сайтында һәм социаль челтәрләр аша аерым хәбәр ителәчәк.

5.7. Конкурска җибәрелгән видеоязмаларны оештыручылар Конгрессның сайтына һәм социаль челтерләренә урнаштырырга хокуклы.